Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 1 (1)
6 октябрь 2011 ел

## • Ике авыз сүз

3 октябрь көнне ректоратның чираттагы утырышы узды. Икътисадый мәсьәләләр һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин ректор Илшат Гафуров җитәкчелегендәге КФУ делегациясенең Германиягә эшлекле сәфәре турында сөйләде. Биредә делегация Ф.Шиллер исемендәге Йена университетында була, Карл Цейс компаниясендә катнаша. Компания кысаларында КФУ базасында микроскопия үзәген булдыру өлкәсендәге хезмәттәшлек турында килешү төзелә.

Ректоратта КФУ брендбугының макетын да тәкъдим итү булды. Аның өстенлеге университет йөзен күрсәтүдә гади һәм җиңел, нәтиҗәле булуда. Сөйләшү барышында, уку йортыбызның татар телендә логотибын булдыру мәсьәләсе күтәрелде, исәпләү математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтында программалаштыру технологияләре кафедрасын оештыру турында тәкъдим ясалды.

• • • •

26 сентябрь көнне КФУ ректораты утырышында Татарстан Республикасы буенча Суд приставларының федераль хезмәт идарәсе җитәкчесе Х.Шәрипов Илшат Гафуровка нәтиҗәле хезмәттәшлеге өчен медаль бирелү турындагы Россия Федерациясе Суд приставларының директоры А.Парфенчиков тарафыннан кул куелган боерыкны укыды. ТР Суд приставларының җитәкчесе бәяләвенчә, КФУ һәм Россия Суд приставларының федераль хезмәт идарәсе арасында урнаштырылган уңай мөнәсәбәтләр уртак перспектив проектлар барлыкка китерде: КФУ студентлары Федераль хезмәттә стажировка үтәләр, галимнәр конференцияләрдә катнашалар. Мисал өчен, 2011 елның җәендә КФУ базасында «Суд карарларын һәм башка органнарның актларын мәҗбүри үтәүнең нәтиҗәлелеге» дигән темага үткәрелгән халыкара фәнни-гамәли конференция үзенә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итте.

• • • •

30 сентябрь КФУда «Лукойл» ААҖ директоры Вахит Алекперов белән очрашу булды. Ул заман икътисадының бүгенге хәле, үсеш перспективалары, проблемалары турында сөйләде. Кара алтын компанияләренең дәрәҗәсенә бәйле фикерләре белән уртаклашты. Ректор Илшат Гафуров: «Вахит Йосыф улына һәм аның хезмәттәшләренә «Лукойл» кампаниясенең 20 еллыгына бәйле бер чараны безнең университетта уздыруны кирәк табулары өчен зур рәхмәт. Моны Казан университеты галимнәренең кара алтын һәм газ җитештерүгә, углеводород эшкәртү технологияләренә бәйле теоретик һәм гамәли хезмәтен зурлау дип кабул итәргә кирәк. Алга таба хезмәттәшлекне тагын да арттырсак иде», – дип белдерде. «Университет сайтында әлеге очрашу уңаеннан калдырган сорауларыгыздан күренгәнчә, сезне бензин бәясе һәм, кара алтын сатып, акча эшләү мәсьәләләре генә кызыксындырмый икән», – диде Вахит Алекперов һәм кара алтын, газ җитештерү кампанияләре алдында торган яңа бурычлар турында сөйләде.

• • • •

Бүген, ягъни 6 октябрь көнне, Казан федераль университетының журналистика һәм социология факультетында Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, телевизион тапшырулар алып баручысы Тина Канделаки катнашында «түгәрәк өстәл» уза. Чарада факультет студентлары һәм укытучылары катнаша. Тина Кандилакиның Казанга килү максаты – ТРның мәгариф системасы белән бәйле телепроектлар әзерләү. Шуңа бәйле рәвештә, ул Казан шәһәренең кайбер мәктәпләрендә сәләтле балалар белән очрашуны да планлаштыра.

*ksu.ru, intertat.ru сайтлары материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы.

# Һәр вузга бушлай Wi-Fi

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

4 октябрь көнне университетыбызда Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорларының утырышы булды. Утырышны Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры Илшат Гафуров алып барды.

Көн тәртибенә уку йортлары өчен бүгенге көндә иң актуаль булган мәсьәләләр куелган иде. Беренче сүз ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Рәфис Борһановка бирелде. Ул чыгышында Универсиадага әзерлекнең югары уку йортларында да спорт үсешенә зур этәргеч булуы, спорт объектларының уналтысы студентлар карамагына тапшырылуы, хоккей, футбол һәм башка төрле спорт уеннары буенча студентлар командаларын җыю турында сөйләде. Киләчәктә бу эшне тагын да җанландырып җибәрү максатыннан чыгып, Татарстанның әйдәп баручы уку йортлары һәм ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы арасында яңа килешүгә кул куелды.

Студентларның хезмәт отрядлары үзәге директоры Ринат Садыйков, быел беренче стуентлар отряды төзелүгә 50 ел тулу уңаеннан, Татарстан студентлар отрядларының Сочи, Болгар, Зөя һ.б. шәһәр яны урман хуҗалыкларында, республиканың алты районында, «Бәләкәч» программасын тормышка ашыру йөзеннән, балалар бакчаларын төзү һәм төзекләндерү эшләрендә катнашуларын әйтеп үтте. Аның чыгышында совет чорындагы студент отрядлары традицияләренә кайту, бүгеннән үк ташчы, бетончы, маляр һ.б. белгечлекләр буенча укыта һәм әзерли башлау кирәк дигән тәкъдимнәр булды.

**Ахыры 2нче биттә.**

# «Әйләнәм дә кайтам шуларга»…

**Сиринә МИҢЛЕГАЛИМ,**
хәбәрче

Казан (Идел буе) федераль университетының филология һәм сәнгать институты каршында эшләп килә торган «Мизгел» яшьләр театрының оешуына быел унбиш ел тулды.

Бу вакыт эчендә театр коллективы шактый җитди әсәрләрне – Туфан Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш», «Кырларым-тугайларым», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Саташу», Әнгам Атнабаевның «Ул кайтты», «Мәхәббәт турында җыр», Хәбиб Фәтхуллинның «Күзләр», Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Йөрәк сере», Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан», Алексей Дударевның «Сагышларым – гомер агышларым» әсәрләрен сәхнәләштереп, тамашачы алдында зур уңышларга иреште.

**Ахыры 3нче биттә.**



# Алар 52 илдән

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

Университет үзенең чит ил студентларын быел да бик җылы кабул итте. 3 октябрь көнне Актлар залында узган очрашу-танышу шул турыда сөйли.

Чарада чит илләрдән килеп белем алучы беренче курс шәкертләре генә түгел, ә өлкәнрәк студентлар, аспирантлар да бар иде. Әүвәл тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, КФУда бүген чит ил студентлары аз түгел – дөньяның 52 иленнән 925 кеше белем ала. «Сезне тырышып укырга чакырам, зачеткаларыгызда бер генә начар билге дә булмасын. Барыгыз да булдыклылар, шуңа күрә дә сезне, ышанып, Россиягә җибәргәннәр. Казан университетында алган белемегезне туган илегездә файдалана алачаксыз», – дип белдерде ул үзенең чыгышында.

Казанда уку, яшәү шартлары һәм башка мәсьәләләргә караган сораулар буенча Татарстан халыклары ассамблеясе, Бөтендөнья татар конгрессы, ТР Президентының Тышкы элемтәләр департаменты һәм хокук саклау органнары вәкилләре дә чыгыш ясады.

Мондый очрашулар университетта традицион рәвештә ел саен үтә. Өченче курс студенты Эммануэль Кабве әйтүенчә, әлеге чара беренче курс студентлары өчен бик мөһим. «Яңа җирлеккә ияләнү, университет һәм бер-беребез белән танышуда чара алыштыргысыз», – диде ул.



Алия Галимуллина фотосы.

# Һәр вузга бушлай Wi-Fi

Башы 1нче биттә.

Кулына кирпеч тә тотып карамаган студентларның бина төзергә килгән очраклары байтак икән.

Казан архитектура-төзелеш университеты, Казан энергетика университеты ректорларына студент хезмәт отрядларының эшен яхшы оештырганнары өчен медаль тапшырылды. Шулай ук Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы һәм республиканың Студентлар хезмәт отрядлары үзәге арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.

Илшат Гафуров Казан федераль университеты студентларының «КФУ – чисталык һәм җыйнаклык территориясе» дигән инициатива белән чыгулары һәм бу эшчәнлекне шәһәр күләмендәдәҗәелдерергә җыенулары турында хәбәр итте. «Әйләнә-тирә мохитне саклау, кайгырту – барыбызның да бурычы ул», – дип белдерде.



Алия Галимуллина фотосы.

ТР уку йортларында наркоманиягә каршы чараларныоештырутурында КФУ ректоры киңәшчесе Виктор Вәлиуллин чыгыш ясады. Ул бу бәладән югары уку йортларында һәм шәһәркүләм елга бер мәртәбә үткәрелгән чаралар ярдәмендә генә котылып булмавы, аны, көн дә зур тырышлык куеп, студетларның бу мәсьәләгә мөнәсәбәтләрен ачыклап, укытучылар белән бергәләп көрәшкәндә генә җиңеп булуга басым ясады.

Илшат Гафуров, югары уку йортларында түләүсез Wi-Fi чыбыксыз элемтә үсешен тизәйтү һәм КФУ базасында барлык уку йортлары өчен бердәм мәгълүмат үзәген төзүне кичектермичә башкарып чыгу өчен, барлык уку йортларыннан фикерләр һәм тәкъдимнәр көтелүен әйтте. Татарстан югары уку йортларына чит илләрдән һәм РФ төбәкләреннән талантлы яшьләрне җәлеп итү, сәләтле балалар өчен интернат тибындагы мәктәпләр төзү буенча концепция әзерләү турында фикерен җиткерде. Академик мобильлекне мактасак та, фән олимпиадаларында җиңүчеләребез Мәскәү югары уку йортларына китеп бару күренеше еш күзәтелә бит.

«Татарстан халыклары мәдәнияте» фәнен укыту һәм ТР дәүләт телләрен саклау, өйрәнү турында филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов сөйләде. Көн тәртибендәге мәсьәләләр арасында югары уку йортлары өчен бердәм поликлиника булдыру, комитет оештыру, вузара телевидение үсешенең юнәлешләрен тәэмин итү, спорт объектларының торышы, алардан файдалану һәм җаваплылык кебек әһәмиятле сораулар да бар иде. Ректорлар советы рәисе Татарстан студентлары арасында Россия суд приставлары институты тарихына һәм хәзерге көндә Федераль суд приставларының эшчәнлегенә бәйле конкурс игълан ителүе турында да хәбәр итте.

• Мөхәррир сүзе



**Рамил ХАННАНОВ**

***Хөрмәтле укучылар!***

*Татар халкы элек-электән башка бик күп халыклардан үзенең белемгә, мәгърифәткә, мәдәният-сәнгатькә, югары культурага көчле омтылышлы, хирыс булуы белән аерылып торган. Мәшһүр Казаныбызда тәүге тапкыр югары гыйлем йорты ачылгач, биредәге шәкертләр милләтебезгә хас шул үзенчәлекле сыйфатларны тагын да камилләштерү юлларын эзләгәннәр. Беренче типографияләр, милли матбугат, театр һәм башка мәдәни үзәкләр оешу шул турыда сөйли.*

*Татарлар төп халык булган Казан мәркәзендә иң абруйлы югары уку йортының да бүгеннән татар телендә чыга торган үз газетасы бар. Моңа кадәр ул республикабызның белем учаклары арасында бары тик ТДГПУда гына нәшер ителә иде.*

*«Дарелфөнүн» – гарәп сүзе. Аның тамырлары ерак гасырларга барып тоташа. Ул «белем йорты», «университет» дигән мәгънәләргә ия. Ике гасырдан артык тарихы булган мәгърифәт һәм фән учагының бай традицияләре ташкынына «Дарелфөнүн» дә бик тиз кушылып китәр дип ышанабыз. Студентларның да, галим-мөгаллимнәрнең, университет хезмәткәрләренең дә әйтер сүзләре, җиткерәсе килгән фикерләре аз түгел. Шулай булгач, хәерле сәгатьтә!*

*Ак юл сиңа, «Дарелфөнүн»!*

• Әдәп-әхлак

# Ә син «культурный»мы?

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Бүгенге көндә дөньяга алсу күзлекләр аша карамыйча, чынбарлыкны күрә белергә өйрәтәләр безне. Аның артында вак-төяк проблемалар, күренмичә, читтәрәк кала. Шуларның берсе культура төшенчәсе.

Әгәр дә сүзлекне ачып, шушы сүзгә тукталсак, анда мондыйрак аңлатманы күрәбез: «Культура» – игү, эшкәртү, «культуралы» – укымышлы. Әйе, культуралы булырга кирәк, дибез, әйбәт булырга телибез. Шулай да күбебез, үзен әйбәт тотарга теләсә дә, моңа ничек ирешергә икәнне белми. Этик яктан тәрбияле булу өчен, шактый тырышырга кирәк. Монда исә өстәл янында ничек утыруың да, гигиена таләпләрен ничек үтәвең дә, тәнеңне ничек күнектерүең дә, үз тирәңдәгеләргә мөнәсәбәтең дә – барысы да бик әһәмиятле. Иң мөһиме шунда: кешеләрнең хәзерге вакытта без бөтенебез омтыла торган иҗтимагый тормыш нормалары әнә шул «вак-төякләрдән» тора. Һәм шушы тышкы культура тәрбиясенә авыл яшьләре (кызганычка каршы, күпләребез шулай уйлый) генә түгел, шәһәр яшьләре, студентлар, мәктәп балалары, ясле-бакчаларга йөрүчеләр – барысы да, шул исәптән, күп санлы олы яшьтәге кешеләр дә мохтаҗ. Без – киләчәк җәмгыятьнең көчле буыны – бөтен яктан да җитлеккән, хезмәт сөючән, намуслы, белемле, укымышлы, акыллы гына түгел, бәлки нәфис тә, матур да, тәрбияле дә булырга тиеш.

Минем никтер белемле, намуслы, әмма үз-үзен тоту нормаларын белмәүче яки аларны танымаучы кешене культуралы дип әйтергә һич кенә дә күңелем бармый. Бу урында А.П.Чеховның сүзләре искә төшә: «Кешенең бөтен ягы да: төсе-бите дә, киеме дә, күңеле дә, фикерләре дә гүзәл булырга тиеш». Дөресе шул. Матур, культуралы кеше ул һәр коллективта бик җиңел һәм тиз хөрмәт яулый. Теләсә-кайсы җәмәгать урынында элементар әйбер булып саналган исәнләшү генә дә безнең никадәр дәрәҗәдә культуралы булуыбызны билгели.

Әйе, беренче тәэсир күп вакыт алдаучан була, диләр. Әмма без кешеләр белән аралашканда, бигрәк тә кешеләр күпләп яши торган урыннарда, университет-мәктәпләрдә кем белән генә очрашмыйбыз. Бәлки, без аларны башка беркайчан күрмәбез дә, димәк, беренче тудырган тәэсиребез соңгы һәм бердәнбер булып калырга да мөмкин. Шулай булгач, үзебезнең культуралы икәнлегебезне һәрдаим сиздереп торыйк. Киләчәктә ишек шакыйсы уңышларыбыз нәкъ менә шундый вак-төякләрдән безнең якка таба юл сорарга мөмкин бит...

• Аталар сүзе – акылның үзе

# Агитбригада җырлары

**Гөлчирә ИМАНКУЛОВА,**
филология һәм сәнгать институты студенты

Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында алып барылган фольклор практикасыннан күренгәнчә, элеккеге вакытта әлеге җирлектә халык җырлары җырланып, яшьләр үзләре дә җырлар иҗат итә торган булганнар

Шуңа мисал итеп, әлеге агитбригада җырларын әйтергә мөмкин. Авыл халкы, яшьләр, ягъни үзешчәннәр әлеге җыр текстларын уйлап табып, аны көйгә салып җырлый торган булганнар. Аларны кырда эшләгән эшчеләрнең ялга туктаган вакытларында, фабрика-цехларда, кич белән клубларда җырлап, халыкның күңелен күреп, эшкә дәртен арттыру максатыннан башкарганнар. Җырларның эчтәлегеннән аңлашылганча, аның һәр строфасы билгеле бер кешенең колхоздагы эшчәнлегенә, авыл кешеләре арасында тоткан урынына карап, холкының билгеле бер үзенчәлеген исәпкә алып язылган. Нәкъ менә шуңа күрә дә алар яратылып башкарылганнар, бик теләп тыңланганнар һәм бүгенгә кадәр саклanганнар.

Зөлкәрәм Абдуллина сөйләгән истәлекләрдән күренгәнчә, Иске Мәңгәр авылы яшьләре агитбригадаларда шундый җырлар җырлаганнар:

*Иртән торып карга куам*
*Кукуруз басуыннан.*
*Хезмәт көне бик аз икән,*
*Үләрсең ачуыңнан.*

***

*Хезмәт көнем аз,кәнишне,*
*Анысы белән мактанмыйм.*
*Әти башка чыгарам,ди,*
*Тик кыз гына таба алмыйм.*

***

*Агитбригада килә дигәч,*
*Председатель чыгып качкан.*
*Кәнсәләргә барып баксак,*
*Бер потлы йозак аскан.*

***

*Бер-ике җыр җырлыйк әле*
*Мәсхүдәгә карата.*
*Үзе яшь кенә булса да,*
*Ялкаулыкны ярата.*

***

*Клуб мөдире Хәбирәгә*
*Акча түләү нәрсәгә?!*
*Стенгазета чыгармый*
*Елына бер мәртәбә.*

***

*Мөхәммәтша абый,*
*тавыкларың*
*Чыпчык булып очалар.*
*Мортазина Факияләр*
*Янында,күп булсалар*

***

*Галиева Хәдичәнең*
*Өч көлтәсе – бер көлтә.*
*Чүмәләләр арасында*
*Нихәл күтәреп йөртә?!*

• «Мизгел»гә 15 яшь

# «Әйләнәм дә кайтам шуларга»...



■ *«Мизгел» театры режиссеры Марсель Җаббаров*

*Башы 1нче биттә.*

## Уңышлар

Сер түгел, бүгенге көндә бик күп уку йортларында театр түгәрәкләре эшли. Күренекле сәнгать әһелләребез тозсыз мәзәккә басым ясап, түбән сыйфатлы әсәрләрне үз итеп, халыкны шаккатырырга маташалар. Әмма Марсель Җаббаров җитәкләгән «Мизгел» театрының чын сәхнә әсәрен профессиональ дәрәҗәдә куя алуы тирән ихтирамга лаек. Кеше дигән бөек затны югары сәнгать әсәре беркайчан да битараф калдырмый, аның кешелеклелек сыйфатларын, әхлагын камилләштерә, эстетик зәвыгын формалаштыра. Әлбәттә, андый әсәрләрне сәхнәгә кую зур көч, тырышлык сорый. Шуның өстенә, булачак укытучылар артист булырга махсус җыелган төркемнән дә түгел, ел саен үзгәреп торган студентлардан артист ясау җиңел генә бирелмидер. Режиссер буларак, Марсель Җаббаров һәр актердан үзе уйный торган геройның эчке һәм тышкы билгеләрен, уй-хисләрен, хәрәкәтләрен тормыш чынбарлыгыннан чыгып сурәтләүне таләп итә. Студентларының нәни генә уңышларына ихлас сөенә, аны үстереп, канатландырып җибәрә.

Театр эшчәнлегенә югары бәя даими рәвештә вакытлы матбугат битләрендә, телевизион тапшыруларда чагылыш таба (беренче куелган өч спектакль телевидение фондында саклана). 2005 елда «Мизгел», республика күләмендә уздырылган «Яшьләр сәхнәсе» конкурсында катнашып, «Иң яхшы спектакль» дипломына лаек була.

Югарыда күрсәтелгән уңышлар, һичшиксез, театрның җитәкчесе Марсель Җаббаров исеме белән бәйле. Шушы унбиш ел эчендә күренекле артист, режиссер, тәрҗемәче, драматург Марсель Җаббаров үзенең әле сизгер психолог һәм оста педагог булуын да раслады. Татар театр сәнгате тарихында да аның үзенең дәрәҗәле урыны бар. Ул тудырган берсеннән-берсе гыйбрәтле образлар һәм тәрбияви рольләр берничә дистә ел дәвамында миллионнарча татарларга, башка төрки халыкларга зур рухи азык һәм әхлакый тәрбия дәресләре дә булып хезмәт итәләр.

«Татар яшьләренең ихласлыгы, сафлыгы һәм эчкерсезлеге, университет җитәкчелегенең теләктәшлеге миңа көч-куәт, дәрт-дәрман өсти», – ди Марсель Җаббаров. Ул сәхнә белән генә чикләнми – һәрвакыт актерлык осталыгын яшьләргә өйрәтә. Аның җитәкчелегендә күп кенә мәктәпләрдә, авылларда үзешчәннәр спектакльләр күрсәтә. Бу спектакльләр хәтта Г.Камал исемендәге театр сәхнәсенә менү бәхетенә ирешә. Шулай да Марсель абыйның зур казанышы – ТДГПУ студентлары һәм укытучылары белән куйган спектакльләр. Т.Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» спектакле аеруча уңышлы, чөнки анда булачак укытучылар үзләрен-үзләре уйный. Марсель абыйның студентлар белән эшләве педагогика университеты өчен күктән төшкән бер бәхет булды. Актерлык серләрен өйрәнү булачак укытучыларның һөнәри осталыкларын да арттыра.

## Халык бәясе

***Әнвәр ХӘЙРИ, галим һәм язучы:***

«Никадәр генә күп образлар тудырса да, аларның берсендә генә дә, ялгышып кына да берсен-берсе кабатлау булмады, аның һәр образы йөрәк жылысын, кайнар темпераментын, көчле дәртен һәм барлык уңай энергиясен салып башкарыла, шунлыктан аны тамашачы да үз итә, ярата, ул уйнаган спектакльләрне кабат-кабат карый иде... Ә моның сере – Марсель Җаббаровның һәр образын фальшсыз, ихластан башкаруында, рольдә чынбарлыктагыча яшәвендә иде... Менә шундый ихлас, чын осталарча итеп башкаруы аркасында, ул тудырган образлар милли театр сәнгате тарихында тирән эз калдырдылар да инде. Ул беркайчан да чиле-пешле халтура белән, рольләрен астан-өстән генә уйнап, татар тамашачысын рәнҗетмәде. Ул үз тамашачысын бик хөрмәт итеп, аларны берсеннән-берсе затлы образлары белән сөендереп торды. Татар тамашачысы аңа шуның өчен бик рәхмәтле. Татар тамашачысы – бик таләпчән һәм сәнгать сөючән халык һәм шушы халыкның чын мәхәббәтен яулау – бик сирәк артистка эләгә торган олы бәхет ул, чөнки аңа үзенең олы бәясен халык үзе бирә. Бу яктан Марсель Җаббаров чын бәхетле Зат. Ул үзенең нәтиҗәле һәм уңышлы хезмәте белән татар театр сәнгате күгендә йолдыз булып балкып калды...

Марсель Җаббаров кебек булдыклы, сәләтле шәхесләр, кая гына барып, нинди генә вазифа башкарса да, аларның хезмәте алдан ук уңышка дучар ителгән була. Чөнки алар хезмәтләрен максатчан итеп оештыра беләләр. Марсель Җаббаров ул начар эшли белми, чөнки аңа өйрәнмәгән. Ул үз үрнәгендә тирә-ягындагыларны да тәрбияли. Аның даирәсендәге кешеләр – барысы да тырышып эшләү чирен йоктыралар да, хәтта аның үзен дә узып китеп, үзеннән дә шәбрәк итеп эшли башлыйлар... Моның ачык мисалы итеп, Марсель Җаббаровның менә ничә еллар инде Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты шәкертләре һәм аспирантлары катнашында талантлы һәм көчле театр оештырып җибәрүен һәм анда бик күп затлы, зәвыклы әсәрләр сәхнәләштерүен, бихисап күп үзе кебек талантлы шәкертләр тәрбияләп үстерүен күрсәтеп була...»

***Рөстәм МАЛИКОВ, педагогика фәннәре докторы, профессор:***

«Мизгел» яшьләр театрының бүлмәсенә кереп чыгуны үзем өчен зур бәхет саныйм. Монда татарның мәшһүр актерлары – Марсель абыйның сәхнәдәш дуслары булган, студентлар белән очрашкан, үзләренең киңәшләрен биргән. Һәркайсының фотосурәтләре диварларга беркетелгән. Бу сурәтләрдән таныш йөзләр – безнең студентларыбыз карап тора, әйтерсең лә чәй эчү процессында алар да катнаша. Марсель абый үзе чәй ясагач, берәм-берәм актер-студентлар җыела. Кемдер кулына баян ала, икенчесе җыр сузып җибәрә. Үзең дә сизмәстән җырга кушылып китәсең, икенчесен башлап җибәрәсең. Лекция-семинарларда тып-тын гына утырган студент бөтенләй башка яктан ачылып китә, үзеннән яхшы укытучы чыгасына практик яктан ышандыра. Ихтыярсыздан, бу балага имтиханда түбән билге куймадыммы икән, дип уйлап куясың. Шулай итеп, чәй эчү процессы мини-спектакльгә әйләнә дә куя. Мондый бәхетле мизгелләрне Марсель абый шикелле осталар гына бүләк итә ала, күрәсең».

***Рамилә МОРАТОВА-АБДУЛЛИНА, Казан шәһәре Г.Ибраһимов исемендәге 17 гимназия укытучысы:***

«Һавада, әбиләр чуагына кушылып, сап-сары яфраклар тантанаиткән,тәрәзәдәнкөзгекояш күзләрне иркәләгән октябрь ае. Марсель Җаббаровның драма түгәрәгенә язылырга теләп җыелган студентлар, тын алырга да онытып, Радж Капурныкын хәтерләткән күпереп торган куе кара чәчле, ыспай гына киенгән сәхнә остасының йомшак кына тавыш белән үтә дә нәзәкатьле итеп укыган «Матурлык» хикәясенә чумган... Сөйләменнән үк җылылык бөркелеп торган артист бераздан хикәя тәэсиреннән айнып та өлгермәгән мөгаллимнәр белән әңгәмә кора... Татар җаны, аның рухы, театр тарихы... 60 студенттан нибары дүртебезгә генә «артист» булу бәхете елмая... Репетиция, сәхнә, беренче рольләр... Марсель абый белән танышу әнә шулай башланды. Тәнәфес вакытларында Марсель абый барыбызны да үз тирәсенә җыя да тудырган образларын шулкадәр җылылык белән сөйли башлый, гүя сәхнәдә аның белән син дә дәртләнеп уйныйсың: бөреләнеп килә торган беренче мәхәббәт утында янасың, шашкын хисләрне кичерәсең, кырыс чынбарлык белән бәрелешеп кайгырасың...»

*«Мизгел» театры 1996 елның сентябрендә РФның атказанган, ТРның халык артисты Марсель Җаббаров җитәкчелегендә КДПУның татар филологиясе факультеты каршында оеша. Театрның беренче артистлары Рамил Мирзаһитов, Илфат Фәсхиев, Рамилә Моратова, Раушания Мингалиева, Эльвира Гарипова, Гөлшат Сәйфуллина, Айдар Җамалиев, Мирсил Әһлетдинов, Раиф Гыймадиевлар була. Бүген төп актерлар - Илназ Баһавиев, Илфат Әхмәдуллин, Алмаз Молдашев, Ләйсән Шәяхмәтова, Фәнүзә Хәсәнова (Габдрахманова), Лениза Гатауллина, Венера Макова, Алмаз Сафиуллин һ.б.*

## Үзе турында үзе

«Минем, билгеле бер уңышка ирешәм дип, үземә максат куйганым юк. Иҗат итәм икән, мин моны уңыш өчен түгел, ә халыкка матурлык күрсәтер өчен эшлим. Уңышка ирешергә теләгән кешегә киңәшем дә шундый: нинди эшкә генә алынса да, күңелен биреп эшләсен иде. Яшь артистларга да һөнәрләренә иҗади карарга киңәш итәм. Уңышның табигый мөмкинлекләрдән генә түгел, ә җитәкчедән дә торганын онытмасалар, бары да әйбәт булыр. Мин үзем яшь артистларны бик яратам, хөрмәт итәм. Аларның уңышлары өчен сөенәм. Инде 15 ел университет студентлары белән эшлим. Монда чын татар атмосферасы, аларның татар телен камил белүләре, рухый чисталыгы, саф күңеллелекләре шатландыра да гаҗәпләндерә. Бүгенге көндә алар – студентлар, ә киләчәктә – укытучылар, шуңа да аларга матурлыкны күрә, балаларны ярата белергә өйрәтәсем килә. Тормыш елданел усаллана, кырыслана бара. Ыгы-зыгыда без хәтта тирәюньдә ниләр булганын да күрми, якыннарыбызның шатлыгына сөенә, кайгысына көенә белми башладык. Тормыш-көнкүреш рәвешебез көннән-көн яхшыру белән беррәттән, кешелеклелек, туганлык, бер-береңә ярдәм итү, мәрхәмәтлелек дигән төшенчәләр онытылып бара. Алар югалмасын. Бер-беребезгә мөмкин булган кадәр ихтирамлы, мәрхәмәтлерәк булсак, бу «өч көнлек дөньяда» туганнарча яшәсәк иде. Шуңададыр, мөгаен, гыйбрәтле, психологик драма әсәрләрен куярга яратам, кеше көлдерә торган әсәрләрне куймыйм мин. Хәзерге драматургия бик чамалы бит. Үземнең күңелем яткан көчле драматурглардан Туфан Миңнуллин, Әнгам Атнабаев, Илдар Юзеев әсәрләрен сайлыйм. Бер 10-15 әсәр алар, әйләнәм дә кайтам шуларга», – ди Марсель Җаббаров.

## Яңа сезон

Марсель Җаббаровның саф татарча сөйләменә сокланмый мөмкин түгел. Ул беркайчан да телләрне бутап сөйләшми. Тормышта да татар сәхнәсе телен саклый. Бу яктан күп кенә укытучыларга, студентларга үрнәк-өлге булып тора.

Табигате белән нечкә күңелле, шигъри җанлы булгангамы, Марсель Җаббаров үзен хыялый кешегә саный. Ә ак канатлы зәңгәр хыяллары булган остаз гомере буе кешелек дөньясына гүзәллек өрергә, шуңа сабыйларча куанырга, матурлыкны күрә, тоя, саклый белергә, һәрвакыт олы җанлы КЕШЕ булып калырга өнди.


Марсель Җаббаровның тагын бер матур сыйфаты турында әйтергә кирәктер. Ул әдәби әсәрләрне күп укый. Андагы геройлар белән яшәп, алар белән хыялланып, кайберләрен сәхнә түренә меңгезә, кабат җанландыра, терелтә. Әйтик, ул Әмирхан Еникинең «Рәшә» повестен сәхнәләштерде, бу спектакльдәге төп рольне үзе үк уйнады. Бүгенге көндә ул яраткан язучысы Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» әсәренә инсценировка язу турында уйлана, мизгелләр белән яңа премьера әзерли. Димәк, безне озакламый тагын бер яңа спектакль көтә.













**Илһам канатында**



**Минлебаева Гөлнар Самат** кызы 1993 елның 18 июлендә Әтнә районының Күәм авылында туа. Бүгенге көндә КФУның филология һәм сәнгать институтында I курста белем ала. Мәктәптә укыганда, өйгә эш итеп укытучылары шигырь язарга биргән була. Шигыреннең шактый уңышлы чыгуын күреп алган остазы ярдәмендә Гөлнар алга таба иҗат эше белән чын-чынлап кызыксынып китә. Өч ел рәттән Бөтенроссия «Илһамлы каләм» конкурсында катнашып, 2011 елда шигъри әсәрләр номинациясендә I урынга лаек була. Мәктәпне тәмамлагач, кайда укырга кирәргә дип озак уйлап тормый ул, бары тик кечкенәдән күңел түрендә йөрткән укытучы булу хыялын чынга ашырырга ашкына. Әсәрләреннән күренгәнчә, Гөлнар Минлебаеваның иҗади киләчәге бик тә өметле. Ә бүген «Илһам канатында» аның уңышлы әсәрләренең берсе белән танышырсыз.

# Черкибашы

*Җәйге тын кич. Капка төбе. Черки халкы бәйрәм итә.*
*Аз гына җил чыкты исә, яртысы кереп качып бетә.*

*Тик качмыйдыр үҗәтләре – кан яраткан ач әрвахы.*
*Алар белән идарә итә борыны китек Черкибашы.*

*Бу кабилә берләштерә ике йөзләп ач черкине,*
*Ә дигәнче сарып ала очыраган бер мескенне.*

*Ә идарә итүчене бик акыллы черки, диләр,*
*Тик нигәдер үз итмиләр идарәгә үрләүчеләр.*

*Менә бүген гадәти кич, дымлы һәм дә бөркү һава,*
*Черки халкы өчен бу кич – җанга рәхәт, тәнгә дәва.*

*Урам башы хәрәкәттә: Зифа әби менеп килә,*
*Илле алты яшь җилкенчәк арык тәннең исен сизә.*

*Миһербанлы Черкибашы,тиз безелдәп,ярып сала:*
*«Юк,тимибез бу әбигә, берәрегез кагылып кара!*

*Гомер буе билен бөкте эссе кырда, фермасында,*
*Колхоз йөген өстерәде шушы арык аркасында.*

*Канын эчте аның һаман зур корсаклы ач бет түрә,*
*Ә пинсәсе – печтик кадәр, көч-хәл белән көнен күрә».*

*Дүрт минутлап вакыт узгач,талгын гына искән җилдә*
*Әллә нинди кислотадай ачы, сасы бер ис килә.*

*Черкибашы таныштыра: «Утыз черки куныгыз,ди,*
*Бу исерекнең аркасына борныгызны тыгыгыз, ди.*

*Әмма ләкин авызына килмәгез сез аның якын,*
*Атна буе эчә инде, ике айлык хезмәт хакын».*

*Утыз черки очып кунды, канын эчеп аңгырайды,*
*Спирт белән кушылган шул, канатлары авырайды.*

*Черкибашы сөйли-сөйли очырадыр егетләрен:*
*«Ялтыравык машинадан чыгып килә Ит бүкәне.*

*Бу бәдбәхет гомере буе РайПО канын эчеп ятты,*
*Пайчыларны алдый-алдый, срогы чыккан товар сатты.*

*Ябышыгыз йөз иллегез, түбенә кадәр суырыгыз,*
*Ачы кислотагыз белән карт пеләшен куырыгыз».*

*Нәкъ йөз илле арык черки сарып алды пеләш башны,*
*Ике кулын болгый-болгый, бу кап-корсак тәмам шашты.*

*Ак күлмәктән кайтып килә, күзлек кигән, портфель тотып,*
*Егерме биш озынборын хәзер алды аны кочып.*

*«Юк,юк,дуслар,тимәгез сез бу мәхлукка, тыныч китсен,*
*Сумкасы тулы дәфтәр аның, әйбәт кенә кайтып җитсен.*

*Хезмәт хакы аз булганга,ашавы да бик аз аның,*
*Итле ризык сирәк эләгә, шуңа күрә тәмсез каны.*

*Бу ел бигрәк эшне аңа олау-олау тоттырдылар,*
*Бу ел синең елың, диеп, буш вәгъдәләр тондырдылар»,–*

*Диеп,Черкибашы дәште үзе белән калганнарны,*
*Җәйләү ягына очып китте, барлар өчен абзарларны.*

# Казанда көз

**Зилә ИБРАҺИМОВА**

*Казанда көз. Минем вакыт килде!*
*Үзгә бер моң иңә җаныма.*
*Җил-яңгыр да – минем стихиям ул,*
*Яздан мине эзләп ялгышма.*

*Казанда көз. Үткән җәйләрне ул*
*Күзен йоммый утта яндыра.*
*Минем күңелдәге тантананы*
*Алтын яңгыр итеп яудыра.*

*Казанда көз. Ә яфраклар гүя*
*Үткәннәрдән килгән пергамент.*
*Тынычланам,илһамланам,сөям...*
*Көз кызыдыр нәкъ тә шуңа мин.*



Энже Ибраһимова фотосы

# Мең урадым Казан урамын

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

БАШКАЛАБЫЗНЫҢ Н.ЕРШОВ УРАМЫНДА БИК МАТУР ҺӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ БЕР ҺӘЙКӘЛ БАР. УЛ 2008 ЕЛДА ТӨЗЕЛӘ.

Бүгенге көндә тормышыбызны телефоннан башка күз алдына китерүе авыр. Ун ел элек кенә әле кәрәзле телефоннарны бик сирәк кешеләрдә күрергә мөмкин иде. Бүген инде аны кече яшьтәге баладан алып, өлкән буын кешеләрендә дә күрергә була. Әмма кәрәзле телефонга кадәр барыбыз да зур, чыбыклы телефоннардан файдаланды. Телефонның электкеге моделен күрергә теләгән кеше Н.Ершов урамындагы «ТАТТЕЛЕКОМ» бинасы каршында Казан элемтәчеләренә багышлап төзелгән һәйкәлне барып карый ала. Анда 1888 елгы элеккеге зур телефонның моделе сынландырылган. Һәйкәлне төзергә Казан сынчысы Асия Миңнуллина алына. Казанда әлеге һәйкәлне бронзадан кою бик күп чыгымнар сорый, әмма «ТАТТЕЛЕКОМ» компаниясе аны тулысынча үз өстенә ала.



**• Рульдә – бичә**



**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

# Мин дә «ЧӘЙНЕК»!

Эт чаба дип, бет чаба дигәндәй, минем дә замана хатын-кызларына хас булган бер сыйфатны күптән үземдә булдырасы килә иде. Икенче курста укып йөргән чакларда аеруча хыялланган идем бу турыда. Сүнеп баручы хыялымны бишенче курста гына чынга ашырырга насыйп булды. Ансы да сеңлем аркасында.

Сүземне ерактан башладым, ахры... Шулай беркөнне сеңлем кайтты да үзенең автомәктәпкә документларын тапшыруын әйтте. «Мин анда сине дә яздым, иртәгә документларын китерер, дип әйттем. Шуңа илтеп тапшыр, миңа сүзе булмасын», – диде. «Син укыячаксыңмы? Вакытың бармы? Иң мөһиме, теләгең бармы? » – дип сораучы кеше булмады.

Алай гына да түгел, акча мәсьәләсе хәл ителгән. Димәк, әнкәй бар нәрсәдән дә хәбәрдар. Шулай итеп, икенче курста белем алучы сеңлем миннән кыюрак булып чыкты...

Бик теләп дәресләргә йөрдем, юл йөрү кагыйдәләрен җентекләп өйрәндем. Сизәм: сеңлем миннән башлырак, лекцияләрне язып тормый, биремнәрне тиз генә чишеп куя. Ләкин рульгә беренче булып миңа утырырга туры килде. Шушы яшемә җитеп, машинаның рулен бер тапкыр гына да тотып караганым булмады... Ю-ю-ю-к, алдыйм икән. 5нче сыйныфта укыганда, безнең машина («Москвич»!) бар иде. Әнкәйнең эшләре буенча, район үзәгенә юл тоттык. Мин машинада калдым. Абый белән әнкәй кибеттә. Кечкенәдән машиналар белән уйнап үскән кыз бала мин, тиз генә руль артына кереп утырдым. Кызык бит, имеш, машина йөртәм. Боргалыйм, баскалыйм гына инде. Карасам, безнең яндагы машинада кеше юк, үзе китеп барды. Көлә-көлә алга борылдым. Ни күрим, кузгалып киткәнмен!!! Мин инде юл уртасында, коймага якынлашып киләм... Күзләремне ачып җибәргәндә, зур-зур абыйлар машинаны тотып калдылар. Каяндыр абый да, әни дә килеп җитте. Нәтиҗәдә, ручникны тартып куярга оныткан абыйга түгел, ә миңа эләкте. Менә шулай итеп мин беренче тапкыр «рулить» иттем.

Тәүге тапкыр руль артына утыруым да бик кызык булды. Башта кузгалып китә алмыйча азапландым. Аннары машинаның туктыйсы килмәде. Я ул сүнеп кала, я бик каты акыра башлый. Беренче мәртәбә «сигезле»не, «гараж»ны ясаганнарым яхшы хәтердә. Бөтен таякны бәреп чыккан чаклар да булды. Шәһәргә чыгып кайткач, аякны тиз генә йөрергә өйрәтеп булмый иде. Әйтерсең, гер такканнар! Ул бөке вакытына эләксәң, синең артта икеләтә бөке барлыкка килә инде.

Бу көн дә җитте. Иртәгә имтихан тапшырырга барасы. Барып бер кат кабатларга, искә төшерергә кирәк... Бетте баш! 6 хата, баганаларны бәреп бетердем... Моңарчы барсын да бик яхшы башкарып килдем дә, менә сиңа! Һаман шул сеңлем инде! Ник әле мин АПА кеше була торып калышырга тиеш?!

Теорияне тапшырып, иң соңгы чыгучы мин булдым! Миңа кадәр тапшырып чыккан 27 кешенеке яшел! Әлбәттә, минеке дә! Шулай итеп, без 100% уңышка ирештек!

Мәйданчыктагы күнегүләрне җиңелдән башкардым үзе. Гаражны тапшырганнан соң гына, «сигез»лене никтер ике урында итеп күрдем. Янымдагы имтихан алучыдан: «По которой проехать?» – дип сорагач: «Я, конечно, вижу, что вы блондинка, но не до такой же степени!» – дигәч, оятымнан җир тишегенә кереп китә идем. Шулай көлешеп, ансы да булды.

Алда Казан урамнары көтә! Тыз-быз чабучы машиналар арасында югалып калмаска кирәк! Монсын да булдырдык! Сеңлем белән икебез дә машина йөртү хокукына ия! Тагын бер максатка ирешелде! Ышанасы да килми бит! Мин дә «чәйнек» булдым. Мин хәзер руль артына курыкмыйча утыра алам! Бездән дә куркырга кирәкми!

Менә шулай, тырышкан табар, ташка кадак кагар, дип юкка әйтмиләр. Хәзерге заманда бер әйбердән дә куркырга, югалып калырга ярамый. Заман белән бергә атларга, максатыңа ирешү өчен, бөтен көчеңне куярга, бар мөмкинлекләрне дә дөрес һәм гадел файдаланырга кирәк!

***P.S.*** *Алга таба да безнең белән бергә бул! Юлдагы кызык хәлләр турында укып бар! Үзең белән юлда булган маҗаралар турында яз. «Рульдә – бичә» икәнен чынлап та исбатлап күрсәтик әле егетләргә!*

DARELFӨNYN университет
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 89053711571. Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru
Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла